**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**07.10.2019** **№ 1706**

**Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдә баш тарту) турында хәбәрнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. “Биектау муниципаль районы” Башкарма комитетының 2018 елның 21 маендагы 1102 номерлы карары белән расланган (2018 елның 9 ноябрендәге 2381 номерлы карар редакциясендә) Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдә баш тарту) турында хәбәрнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр, гариза бирүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны күрсәтү тәртибе | 1) бинаны күчерү турында гариза;<br>2) күчерелә торган бинага хокук билгеләүче документлар (төп нөсхәләр яки нотариаль тәртиптә расланган күчермәләр);<br>3) күчерелә торган бинаның аның техник тасвирламасы белән планы (әгәр дә күчерелә торган бина торак булса, әлеге бинаның техник паспорты);<br>4) күчерелүче бина урнашкан йортның катлар планы;<br>5) билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән һәм рәсмиләштерелгән күчерелүче бинаны яңадан төзү һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру | РФ ТКның 2 п. 23 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | проекты (әгәр үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру мондый бинаны торак яки торак булмаган бина сыйфатында файдалануны тәэмин итү өчен кирәк булган очракта);<br>6) күпфатирлы йортта биналар милекчеләренең торак бинаны торак булмаган бинага күчерүгә ризалыгы турында карарны үз эченә алган гомуми җыелыш беркетмәсе;<br>7) күчерелә торган бина белән янәшә барлык биналарның һәр милекчесенннән торак бинаны торак булмаган бинага күчерүгә ризалыгы.<br>Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин.<br>Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм кушымта итеп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелде) мөмкин:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эшләүче зат тарафыннан);<br>почта аша җибәрү.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми | |

| | | |
|---|---|---|
| | файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән “Интернет” телекоммуникация челтәре һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |

2) 2.9 пунктының 5 пунктчасында “торак биналарны” сүзләрен “күпфатирлы йорттагы биналар” сүзләре белән алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф.Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин